# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Юл хәрәкәте, транспорттан файдалану һәм аны саклау, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

"Юл хәрәкәте, транспорттан файдалану һәм аны саклау, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, 5,6-7 нче саннар; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995 ел, 7-8 нче сан), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

"Юл хәрәкәте, транспорттан файдалану, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

<u>1 статья.</u> Транспорт чараларын йөртүчеләрнең Юл хәрәкәте кагыйдәләрен яисә транспорт чараларыннан файдалану кагыйдәләрен җиңел тән җәрәхәтләре ясарлык яисә матди зыян китерерлек итеп бозулар

Транспорт чараларын йөртүчеләр Юл хәрәкәте кагыйдәләрен яисә транспорттан файдалану кагыйдәләрен матди зыян китерерлек

итеп бозган өчен -

хезмәт өчен түләүнең икедән алып алты минималь күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр Юл хәрәкәте яисә транспорт чараларыннан файдалану кагыйдәләрен җиңел тән җәрәхәтләре ясарлык итеп бозган өчен -

хезмәт өчен түләүнең өчтән алып сигез минималь күләменә кадәр штраф салына яисә алар транспорт чараларын йөртү хокукыннан ике айдан алып алты айга кадәр мәхрүм ителә.

2 статья. Транспорт чараларын теркәү һәм алардан файдалану кагыйдәләрен бозу

Транспорт чараларын теркәү кагыйдәләрен бозган өчен -

гражданнарга - хезмәт өчен түләүнең 0,1 дән алып 0,5 һәм урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең 0,5 тән алып бер минималь күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр дәүләт техник каравы узмаган яисә Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә алардан файдалануны тыючы төзексезлеге булган (моңа әлеге статьяның өченче, алтынчы, җиденче өлешләрендә күрсәтелгән төзексезлекләр керми) транспорт чараларын йөрткән өчен -

кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең 0,1 дән алып 0,3 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр тормоз системасында, руль идарәсендә төзексезлеге булган яисә тарту-тоташтыру җайланмасы (автопоезд составында) төзек булмаган транспорт чараларын йөрткән өчен -

хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләмендә штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр дәүләт теркәү тамгалары булмыйча, шул исәптән йөк машиналары һәм җиңел автомобильләрнең прицепларында да, шулай ук ялган дәүләт теркәү тамгалары белән транспорт чараларын йөрткән өчен -

хезмәт өчен түләүнең ике минималь күләмендә штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр стандарт булмаган, укып булмаслык яисә Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган килеш урнашты-

рылган дәүләт теркәү тамгалы транспорт чараларын йөрткән өчен -

кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең 0,1 дән 0,3 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясе рөхсәтеннән гайре автранспорт чараларында махсус яктылык һәм тавыш сигналлары бирү җайланмалары урнаштырган өчен, автомобильләрнең алгы ягына кызыл утлар, яктылык кайтаргыч кызыл җайланмалар яисә яктылык кайтаргыч кызыл материаллар урнаштырган өчен, шулай ук оператив хезмәтләр автомобильләренең төсле графика схемаларын законсыз кулланган өчен -

транспорт чараларын йөртүчеләргә һәм аларның биләүчеләренә - хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләмендә, транспорт чараларыннан файдалануда җаваплы урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең ике минималь күләмендә штраф салына.

Транспорт чараларын йәртүчеләр, үзләре утырган урыннан күрү мөмкинлеген чикләүче һәм билгеләнгән кагыйдәләрнең таләпләренә туры килми торган яктылык үткәрү ысуллары белән яисә тонлы көзге алымы белән пыялага япмалар ясалган транспорт чараларыннан файдаланган өчен -

хезмәт өчен түләүнең ике минималь күләмендә штраф салына.

<u>3 статья.</u> Транспорт чараларын йөртү хокукы булмаган затларның транспорт чараларын йөртүе

Транспорт чараларын йөртү хокукына Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган документларын үзе белән алмыйча гына транспорт чараларын йөрткән өчен -

хезмәт өчен түләүнең 0,1 дән алып 0,3 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Шушы транспорт чараларын йөртергә хокукы булмаган затлар транспорт чараларын йөрткән өчен, шулай ук йөртү хокукы булмаган затка транспорт чарасын йөртүне тапшырган өчен -

хезмәт өчен түләүнең өчтән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. Транспорт чараларын йөртүчеләрнең Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуы

Ябылган яисә ябылып килүче шлагбаумда, светофорның тыю сигналы яисә тимер юл аша аркылы чыгу урынында кизү торучының тыю сигналы вакытында тимер юл аша хәрәкәт иткән өчен -

хезмәт өчен түләүнең өчтән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына яисә транспорт чараларын йөртү хокукыннан өч айдан алып алты айга кадәр мәхрүм итү карала.

Юл тамгаларын һәм транспорт йөрү урыннарын билгеләү, транспорт чараларын йөрү урыннарында урнаштыру таләпләрен сакламаган өчен, тукталыш, туктап тору, буксирлау һәм пассажирлар йөртү, йөк ташу кагыйдәләрен, тышкы яктылык приборларыннан, тавыш сигналларыннан, куркынычсызлык каешларыннан һәм мотошлемнардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен, тимер юл аша аркылы чыгу кагыйдәләрен (моңа беренче өлештә күрсәтелгән очраклар керми), торак зоналарында хәрәкәт итү һәм туктап тору кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең 0,2 дән алып 0,5 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр хәрәкәтнең билгеләнгән тизлеген 10нан алып 30 км/сәгатькә кадәр арттырган өчен, җәмәгать транспорты тукталышларын, җәяүлеләрнең юл аша чыгу урыннарын узып китү, капма-каршы юнәлешләрдәге транспорт агымнарын бүлүче тоташ сызыкларны кисеп чыгу кагыйдәләрен, маневрлау, юл чатлары аша узу кагыйдәләрен бозган өчен, хәрәкәттә өстенлек хокукына ия булган транспорт чараларын йөртүчеләргә яисә җәяүлеләргә бу өстенлекне бирмәгән өчен -

хезмәт өчен түләүнең бердән алып ике минималь күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр хәрәкәтнең билгеләнгән тизлеген 30 км/сәгатьтән арттырган өчен, светофорның яисә юл хәрәкәтен җайга салучының тыю сигналына карамастан, узып киткән өчен, узып китү кагыйдәләрен бозган өчен -

хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләмендә штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр хәрәкәтнең билгеләнгән тизлеген "Балалар", "Куркыныч" юл тамгалары гамәлдә булган зонада 10 км/сәгатьтән арттырган өчен -

хезмәт өчен түләүнең бердән алып өч минималь күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр әлеге Закон статьяларында каралганнардан гайре башка юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең 0,2 минималь күләмендә штраф салына.

Искәрмә. Транспорт чараларының туктап тору, тукталыш кагыйдәләрен бозганда блокирлаштыру җайланмаларын куллану, транспорт чараларын эвакуацияләү, номер тамгаларын салдырып алу, әлеге Законда каралмаган башка гамәлләр куллану тыела.

5 статья. Юл хәрәкәтенә комачауларлык итеп, төркем-төркем хәрәкәт итү

Транспорт чараларын йөртүчеләр юлларда, шәһәрләр һәм башка торак пунктлары урамнарында юл хәрәкәтенә комачауларлык итеп, төркем-төркем хәрәкәт итүләрдә катнашкан өчен яисә тавыш сигналларын куллану кагыйдәләрен бозып катнашкан өчен -

хезмәт өчен түләүнең бер ярымнан алып ике минималь күләменә кадәр штраф салына.

6 статья. Транспорт чараларын йөртүчеләрнең исерек хәлдә транспорт чараларын йөртүе

Транспорт чараларын йөртүчеләр исерек хәлдә транспорт чараларын йөрткән өчен, шулай ук исерек хәлдәге затка транспорт чарасын йөртүне тапшырган өчен -

хезмәт өчен түләүнең дүрттән алып сигез минималь күләменә кадәр штраф салына яисә алар транспорт чараларын йөртү хокукыннан бер елга мәхрүм ителә.

Ел дәвамында кабат шул ук гамәлләрне кылган өчен -

хезмәт өчен түләүнең алтыдан алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына яисә алар транспорт чараларын йөртү хокукыннан бер елдан алып өч елга кадәр мәхрүм ителә.

7 статья. Транспорт чараларын йөртү хокукына ия булмаучы һәм исерек хәлдәге затларның транспорт чараларын йөртүе

Транспорт чараларын йөртү хокукы булмаучы һәм исерек хәлдәге затлар транспорт чараларын йөрткән өчен -

хезмәт өчен түләүнең сигездән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

Ел дәвамында кабат шул ук гамәлләрне кылган өчен -

хезмәт өчен түләүнең уннан алып унике минималь күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Хәрәкәттә катнашучылар тарафыннан милиция хезмәткәренең законлы таләпләре яисә күрсәтмәләре үтәлмәү

Транспорт чараларын һәм юл механизмнарын йөртүчеләр милиция хезмәткәренең юл-транспорт вакыйгаларындагы тискәре нәтиҗәләрне бетергәндә бушлай ярдәм күрсәтү буенча таләпләрен яисә күрсәтмәләрен үтәмәгән өчен -

хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләмендә штраф салына.

Транспорт чараларын йөртүчеләр милиция хезмәткәренең кул ишарәсе белән, жезл, сыбызгы яисә тавыш көчәйткеч җайланмалар белән сигнал биреп транспорт чараларын туктату турындагы законлы таләпләрен үтәмәгән өчен -

хезмәт өчен түләүнең бердән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына яисә алар бер елдан өч елга кадәр транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителә.

Транспорт чараларын йөртүчеләр билгеләнгән тәртип нигезендә исереклек халәтен таныклауны үтәүдән баш тарткан өчен -

хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына яисә алар ике елдан алып өч елга кадәр транспорт чараларын йәртүдән мәхрүм ителә.

9 статья. Транспорт чараларын йөртүчеләрнең юл-транспорт вакыйгалары булган урыннарны ташлап китүләре

Транспорт чараларын йөртүчеләр, үзләре катнашында булган

юл-транспорт вакыйгалары урыннарын, Юл йөрү кагыйдәләрен бозып ташлап киткән өчен -

хезмәт өчен түләүнең дүрттән алып сигез минималь күләменә кадәр штраф салына яисә алар бердән алып ике елга кадәр транспорт чаралары йөртүдән мәхрүм ителә.

10 статья. Җәяүлеләрнең һәм юл хәрәкәтендә башка катнашучыларның Юл хәрәкәте кагыйдәләре бозуы

Җәяүлеләр Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен -

хезмәт өчен түләүнең 0,1 дән алып 0,3 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Мопедларда, велосипедларда йөрүчеләр Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен, шулай ук пассажирлар йөртүчеләр, пассажирлар яисә юл хәрәкәте процессында турыдан-туры башка катнашучылар Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен -

хезмәт өчен түләүнең 0,1 дән алып 0,5 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә күрсәтелгән исерек хәлдәге затлар Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен -

хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләмендә штраф салына.

Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә күрсәтелгән затлар Юл хәрәкәте кагыйдәләрен җиңелчә тән җәрәхәтләре ясарлык яисә матди зыян китерерлек итеп бозган өчен -

хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләмендә штраф салына.

11 статья. Транспорт чараларының техник торышы һәм алардан файдалану өчен җаваплы урындагы затларның юл йөрү хәвефсезлеген тәэмин итү бурычларын үтәмәүләре

Төзек булмаган һәм файдалану тыелган транспорт чараларын линиягә чыгарган яисә аларны тиешле рөхсәтсез үзгәртеп җиһазлаган өчен яки билгеләнгән тәртиптә теркәлмәгән яисә, дәүләт техник каравын узмаган килеш, транспорт чараларын линиягә чыгарган өчен -

транспорт чараларының техник торышы һәм алардан файдалану өчен җаваплы урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең бердән алып өч минималь күләменә кадәр штраф салына.

Транспорт чараларын исерек хәлдә йөртүчеләрне яисә транспорт чараларын йөртергә хокуклары булмаган затларны транспорт чараларын йөртүгә чыгарган өчен -

хезмәт өчен түләүнең икедән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

<u>12 статья.</u> Юлларны, юл хәрәкәтен җайга салу буенча техник чараларны тоту кагыйдәләрен, юлларда эшләр башкару кагыйдәләрен бозу, юл хәрәкәтендә комачаулыклар китереп чыгару

Юлларны, тимер юл аша аркылы чыгу урыннарын, юл хәрәкәтен җайга салу буенча башка техник чараларны тоту кагыйдәләрен, шулай ук юллар астындагы тикшерү коеларын, җир асты коммуникацияләрен тоту кагыйдәләрен бозган өчен, аларны юлдагы хәрәкәт өчен имин хәлдә тотмаган яисә юлдагы хәрәкәт өчен кимчелекләрне үз вакытында бетерү чараларын күрмәгән өчен, юлларның аерым өлешләрендә шулар нәтиҗәсендә хәвефсезлек куркынычы тудырган өчен, юл-урам челтәрен ремонтлаганда тиешле юл тамгаларын тиешенчә урнаштырмаган өчен -

юллар торышы өчен, тимер юл аша аркылы чыгу урыннары өчен һәм башка юл корылмалары һәм коммуникация хуҗалыклары өчен җаваплы урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

Юлларда һәм автомобиль юллары полосасында рөхсәтсез (ордерсыз) җир казу эшләре башкарган, җир казу эшләрен башкару вакытларын үтәмәгән, асфальт өстен, газоннарны һәм автомобиль юллары полосаларын эшләр тәмамланганнан соң үз хәленә китермәгән яисә тиешенчә китермәгән өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләмендә, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ике минималь күләмендә штраф салына.

Юлларны, тимер юл аша аркылы чыгу урыннарын, юл хәрәкәтен җайга салуның башка техник чараларын зарарлаган, юл тамгаларын Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясе бүлекчәләре белән

293



килешмичә урнаштырган, шулай ук юл хәрәкәтен кыенлаштырган өчен, шул исәптән юл өстен пычратып та, -

хезмәт өчен түләүнең бердән алып ике минималь күләменә кадәр штраф салына.

13 статья. Автомобиль транспортында хәвефле, зур күләмле һәм авыр йөкләр ташу кагыйдәләрен бозу

Хәвефле, зур күләмле һәм авыр йөкләрне автомобиль транспортында ташу кагыйдәләрен бозган өчен, -

транспорт чараларын йөртүчеләргә - хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләмендә, ә йөкләрне ташу өчен җаваплы урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

Хәвефле, зур күләмле, авыр йөкләрне ташу кагыйдәләрен элемтә челтәрләрен өзәрлек, транспорт чараларына, юлларга, йөкләргә, юл корылмаларына һәм башка корылмаларга яисә башка мөлкәткә зыян китерерлек итеп бозган өчен -

транспорт чараларын йөртүчеләргә - хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләмендә, ә йәкләрне ташу өчен җаваплы урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып сигез минималь күләменә кадәр штраф салына.

14 статья. Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясенең законлы күрсәтмәләрен үтәмәү

Юл хәрәкәте хәвефсезлеген тәэмин итүгә караган кагыйдәләрне, нормаларны һәм стандартларны бозу турында Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясенең законлы күрсәтмәләрен үтәмәгән өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең бердән алып өч минималь күләменә кадәр штраф салына.

Ел дәвамында Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясенең элек бирелгән законлы күрсәтмәсен кабат үтәмәгән өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

15 статья. Административ хокук бозу турында беркетмә төзү тәртибе

Административ хокук бозу турындагы беркетмә Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясенең яисә юл-патруль хезмәтенең инспекторлары, эчке эшләр органнарының урындагы вәкаләтле башка затлары, хәрби автомобиль инспекциясе инспекторлары, шулай ук җәмәгать инспекторлары һәм дружинниклары тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә төзелә һәм биш көн эчендә административ хокук бозуларны карарга вәкаләтле органга (урындагы затка) җибәрелә.

Беркетмәдә бөтен реквизитлар тутырыла, эшне хәл итү өчен кирәкле башка белешмәләр күрсәтелә. Аңа хокук бозучының аңлатмасы кушып бирелә. Беркетмә, аны төзүче зат һәм административ хокук бозучы тарафыннан имзалана; шаһитлар һәм зыян күрүчеләр булганда беркетмәгә алар да кул куярга мөмкин.

Административ хокук бозу турындагы беркетмәнең күчермәсе беркетмә төзелгәч үк кичекмәстән, имзасын алып, административ хокук бозган затка, шулай ук үтенече буенча зыян күрүчегә тапшырыла.

Әгәр дә хокук бозучы хокук бозуга һәм әлеге Законның 2 статьясындагы беренче, икенче, өченче, бишенче, алтынчы өлешләрендә, 3 статьясындагы беренче өлешендә, 4 статьясының икенче, алтынчы өлешләрендә, 8 статьясындагы беренче өлешендә, 10 статьяның беренче, икенче, өченче өлешләрендә каралган штрафларга карата ризасызлык белдермәсә, беркетмә төзелми. Бу очракларда салына торган штрафлар хокук бозу урынында ук гамәлдәге законнар нигезендә алына. Штраф алу турында хокук бозучыга билгеләнгән үрнәктәге квитанция бирелә, ул исә катгый финанс хисабы документы булып тора. Шул ук урында штраф түләү мөмкинлеге булмаганда, Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясенең урындагы заты карар чыгарып беркетмә төзи.

16 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәкаләтле урындагы затлар

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм эчке эшләр органнары исеменнән адми-

нистратив җәза бирергә түбәндәгеләр хокуклы:

1) бу Законда каралган административ хокук бозулар өчен - республиканың, шәһәрләрнең, районнарның баш Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясе инспекторлары яисә аларның урынбасарлары;

2) бу Законның 2 статьясында, 3 статьясында, 4 статьясындагы икенче, өченче, дүртенче, бишенче һәм алтынчы өлешләрендә, 5 статьясында, 8 статьясының беренче өлешендә, 10 статьясында каралган административ хокук бозулар өчен - юл-патруль хезмәтенең полк, батальон, рота, бүлекчәләре командирлары һәм аларның урынбасарлары, юл-патруль хезмәтенең һәм административ хокук куллану эшчәнлегенең бүлек һәм бүлекчә башлыклары;

3) бу Законның 2 статьясындагы беренче, икенче, әченче, бишенче, алтынчы өлешләрендә, 3 статьясындагы беренче өлешендә, 4 статьясындагы икенче, алтынчы әлешләрендә, 8 статьясындагы беренче өлешендә, 10 статьясындагы беренче, икенче, өченче өлешләрендә каралган административ хокук бозулар өчен - Юл хәрәкәте хәвефсезлеге дәүләт инспекциясенең барлык хезмәткәрләре, юл-патруль хезмәтенең махсус белеме булган инспекторлары.

Бу Законда каралган хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкка тарту турында күрсәтелгән урындагы затлар тарафыннан дәлилләнгән карар чыгарыла.

17 статья. Транспорт чараларын тоткарлау

Транспорт чараларын исерек килеш йөрткән өчен яисә Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган документлар булмаганда эчке эшләр органнарының урындагы затлары транспорт чараларын тоткарларга һәм аларны махсус сакланылучы тукталышларга (саклаган өчен түләү белән) куярга хокуклы.

Транспорт чарасын тоткарлау сәбәпләре бетерелгәннән соң һәм тиешле штрафны түләгәч, Юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган тиешле документлары булса - транспорт чарасы хуҗасына, ә йөртү хокукы документы булмаганда, йөртү хокукына тиешле документлары булган ышанычлы затка кире кайтарып бирелә.

Транспорт чарасын һәм ташыла торган йөкне тоткарлау аерым

акт белән рәсмиләштерелә, административ хокук бозулар турындагы беркетмәдә тиешенчә язылa.

Транспорт чарасын һәм ташыла торган йөкне саклау, саклаган өчен түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Транспорт чарасын тоткарлаган урындагы зат законнар нигезендә аның хуҗасына китерелгән зыян өчен җаваплы була.

Искәрмә. Транспорт чарасын йөртү хокукына документ күрсәткәч, тоткарланган транспорт чарасы үз хуҗасына кичекмәстән кайтарып бирелә.

18 статья. Транспорт чараларын йөртүчеләрне һәм транспорт чараларын йөртүче башка затларны таныклау

Транспорт чараларын йөртүчеләрнең һәм башка затларның исерек килеш машина йөрткәнлекләрен раслый торган нигезләр булса, исереклек халәте билгеләнгән тәртиптә таныкланырга тиеш.

Әлеге затларның исереклек халәтен тикшерү һәм таныклау Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

19 статья. Транспорт чарасын йөртү таныклыгын алып калу һәм аны кире кайтарып бирү тәртибе

Беркетмә төзелә торган Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган очракта, транспорт чараларын йөртүчедән бу эш буенча карар үтәлгәнчегә кадәр, аны йөртү таныклыгы алып калына һәм транспорт чарасын йөртү хокукына вакытлыча рөхсәт бирелә, бу хакта беркетмәдә языла.

Транспорт чараларын йөртү хокукыннан алты айга һәм аннан да озагракка мәхрүм ителгән йөртүчегә транспорт чараларын йөртү таныклыгы Юл хәрәкәте кагыйдәләрен һәм йөртү күнекмәләрен белүенә тикшерү үткәрелгәннән соң кире кайтарып бирелә.

20 статья. Транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм итү турындагы вакытларны исәпләү

Транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм итү турында карар чыгарылган көннән транспорт чараларын йөртүче транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән дип санала.

Транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителгән транспорт чараларын йөртүче йөртү таныклыгын (транспорт чараларын йөртү хокукына вакытлы рөхсәтне) бирүдән баш тартканда, бу чор аны тартып алган мизгелдән, әмма транспорт чараларын йөртү хокукыннан мөхрүм итү вакыты чыкканчы исәпләнелә.

Транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм ителү чоры гражданның (гражданнарның), барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның үтенечнамәсе буенча әлеге хокуктан мәхрүм итү вакытының кимендә яртысы үткәннән соң җәза биргән орган (урындагы зат) тарафыннан кыскартылырга мөмкин."

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 24 июне
№ 1688